КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № б-1801

Халыкара өлкәннәр көнен әзерләү һәм үткәрү эшен оештыру, җәмәгатьчелек игътибарын өлкән яшьтәге кешеләр мәсьәләләренә җәлеп итү, аларга ярдәм күрсәтү һәм булышу максатларында:

1. 2021 елның октябрендә Татарстан Республикасында, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, Халыкара өлкәннәр көненә багышланган чаралар үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2021 елның 20 сентябренә кадәр Халыкара өлкәннәр көненә багышланган чаралар планын эшләргә һәм расларга, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен исәпкә алып, аның үтәлешен оештырырга, шул исәптән ведомство буйсынуындагы оешмаларның өлкән яшьтәге гражданнарга шефлык итүен оештыру буенча кирәкле чаралар күрергә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм өлкән яшьтәге гражданнарга медицина һәм дару белән тәэмин итү ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетында һәм «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе бюджетында каралган акча кысаларында аларга әлеге максатларда законнар нигезендә өстенлекле тәртиптә ярдәм күрсәтүне;

аз хәрәкәтләнүче, ялгыз һәм ялгыз яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм өлкән яшьтәге гражданнар өйләрендә булуны;

сәламәтлек саклау оешмаларында Халыкара өлкәннәр көне кысаларында аерым категорияләрдәге гражданнарның медицина хезмәте күрсәтү һәм дару белән тәэмин итү өлкәсендә хокуклары турында мәгълүмат бирү характерындагы стендлар, элмә такталар һәм аншлаглар урнаштыруны.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балигъ булмаганнарны тәрбияләүче өлкән яшьтәге опекуннарга ярдәм күрсәтү чараларын күрергә.

5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

пенсионерларның һәм ветераннарның республика, шәһәр, район оешмаларына Халыкара өлкәннәр көненә Татарстан Республикасының театр-тамаша учреждениеләренә чакыру билетлары бирүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә Халыкара өлкәннәр көненә багышланган «Өлкәннәр декадасы» социомәдәни акциясен үткәрүне.

6. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына өлкән яшьтәге гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү эшен оештырырга.

7. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына:

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен исәпкә алып, өлкән яшьтәге гражданнар өчен мәдәният, спорт һәм туристлык объектларына керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

пенсионерларның һәм ветераннарның республика, шәһәр, район оешмалары белән берлектә, социаль туризмны үстерү кысаларында тарихи-мәдәни мирас объектларына, спорт объектларына экскурсияләр оештырырга.

8. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, яшьләр иҗтимагый оешмалары, пенсионерлар һәм ветераннар оешмалары белән берлектә:

физик культура, спорт һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмаларда өлкән яшьтәге гражданнарның физкультура-сәламәтләндерү дәресләрен үткәрү өчен шартлар тудырырга;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, физик культура белән шөгыльләнүләрне, актив озын гомерлелекне популярлаштыруга юнәлдерелгән массакүләм физкультура чаралары үткәрергә.

9. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә бу боерыкның 7, 8 пунктларында күрсәтелгән чараларны оештыруда катнашуны тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

аерым категорияләрдәге өлкән яшьтәге гражданнарның чираттан тыш һәм ташламалы хезмәт күрсәтүгә хокуклары турында мәгълүмат биреп, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында өлкән яшьтәге гражданнарга хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләренә аерым игътибар итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасында Халыкара өлкәннәр көненә багышланган чараларны әзерләү һәм үткәрү буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе

таләпләрен исәпкә алып, ведомство буйсынуындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында әлеге чараларны үткәрүне оештырырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының Халыкара өлкәннәр көне кысаларында үткәрелгән чаралары турындагы мәгълүматын гомумиләштерергә һәм 2021 елның 1 ноябренә кадәр аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Халыкара өлкәннәр көне кысаларында үткәрелә торган чараларны республика һәм район массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

12. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына Халыкара өлкәннәр көне кысаларында чаралар оештыру һәм үткәрү турындагы мәгълүматны гаиләләргә һәм өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарга ярдәм итү йөзеннән эшләүче коммерциягә карамаган оешмалар җитәкчеләренә җиткерергә.

13. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә:

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен исәпкә алып, тормышта авыр хәлдә калган ялгыз гражданнарга аеруча игътибар итеп, өлкән яшьтәге гражданнарга матди, социаль-көнкүреш, медицина-социаль, психологик һәм башка ярдәм күрсәтү максаты белән социаль әһәмиятле акция буларак Халыкара өлкәннәр көненә багышланган чаралар үткәрүне;

«Россия пенсионерлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Россия пенсионерлар берлегенең муниципаль берәмлекләрдәге җирле бүлекләре белән хезмәттәшлек итеп, өлкән яшьтәге гражданнарны «Өченче яшьтәгеләр» университеты программалары буенча укытуны, шул исәптән компьютер белеме бирүне оештыруны;

һәркем алырлык бәяләргә азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар ярминкәләрен оештыруны тәэмин итүне;

Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында, ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмалары белән берлектә, өлкән яшьтәге гражданнарны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү өчен махсуслаштырылган вакансияләр ярминкәләрен, өлкән буын затларына финанс белеме бирү чараларын оештыруны;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан предприятиеләр җитәкчеләренең элек хезмәт коллективларында эшләгән өлкән яшьтәге гражданнар белән очрашуларын үткәрүне һәм аларга матди ярдәм күрсәтүне тәэмин итүне;

пенсионерларның һәм ветераннарның республика, шәһәр, район оешмалары белән берлектә, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарның матди-көнкүреш хәлен тикшерүне, алга таба аларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүне оештыруны;

йорт янындагы территорияләрне, паркларны һәм скверларны төзекләндерү һәм өлкән яшьтәге гражданнар ял итү өчен шартлар тудыру буенча чаралар күрүне;

Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү мәсьәләләренә игътибарны көчәйтүне;

Татарстан Республикасы оешмаларына түбәндәгеләрне башкаруны:

өлкән яшьтәге гражданнарга ташламалы бәяләргә товарлар һәм азык-төлекне махсуслаштырылган сатуны, чәчтарашханәләрдә, мунчаларда хезмәт күрсәтүне;

ашханәләрдә көндезге хәйрия ашларын үткәрүне;

Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшмәкәрләре ассоциациясенә, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясенә, Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасына, хәйрия фондларына өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш шартларын яхшыртуга һәм аларга ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуны.

14. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2021 елның 13 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Халыкара өлкәннәр көне кысаларында үткәрелгән чаралар турында йомгаклау мәгълүматын кертергә, шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә әлеге йомгаклау мәгълүматын кертүне тәкъдим итәргә.

15. Бу боерыкның 3 – 8 пунктларында, шулай ук 10 – 11 пунктларында күрсәтелгән чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслау 2021 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчеләр буенча каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

16. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин